**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительного комитета Азнакаевского муниципаль районы**

Ленин ур., 22 й., Азнакай ш., 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**"03" ноябрь 2022 ел** **№343**

Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 22 декабрендәге 345 номерлы «2020-2025 елларга Азнакай муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында (2021 елның 19 октябрендәге 263 номерлы карары редакциясендә)

«Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 03 октябрендәге 88 номерлы карары белән расланган,«Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 03 февралендәге 52 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы карары белән расланган, «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» ярдәмче программасына үзгәреш кертү турында» 2021 елның 25 сентябрендәге 916 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән, карар итә:

1. Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 22 декабрендәге 345 номерлы «2020-2025 елларга Азнакай муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» карарына (2021 елның 19 октябрендәге 263 номерлы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1. «Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Программа чараларын финанслау федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән планлаштырыла, финанслау күләме дәүләт заказчысы - Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы

тарафыннан бүлү нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

| ел | Күздә тотылган акча күләме-мең сум | | |
|---|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы бюджеты | Федераль бюджет | Бюджеттан тыш чыганаклар |
| 2020 | - | - | - |
| 2021 | 562 462,25 | 116 917,15 | 1 585 218,6 |
| 2022 | 1 360 900,95 | 489 094,05 | 3 435 705,00 |
| 2023 | * | * | * |
| 2024 | * | * | * |
| 2025 | * | * | * |

*Чараларны финанслау күләмнәре Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгында конкурс нигезендә сайлап алу йомгаклары буенча ел саен төгәлләштерелергә тиеш.

23 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көнлек срокта торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыкны һәм Түләүгә сәләтне 21 пункт нигезендә раслаган яшь гаиләләргә планлаштырыла торган елда социаль түләүләр алуга дәгъва кылучы яшь гаиләләр исемлеген формалаштыру турында мәгълүмат (Бердәм портал ярдәмендә язмача яисә электрон рәвештә);».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru, «Идарә» дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасында урнаштырырга, Азнакай муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад һәм финанс буенча урынбасары О.Н. Газизовага йөкләргә.

Җитәкче А. Х. Шәмсетдинов